ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап турында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерүгә һәм икътисад өчен кадрлар әзерләүгә керткән зур өлешен, республиканың социаль өлкәсе өчен кадрларны яңадан әзерләүдә һәм аларның квалификациясен күтәрүдә катнашуын, сәламәтлек саклау системасын алгарышлы үстерүгә керткән өлешен, икътисадның чынбарлыктагы секторы, социаль өлкә тармаклары өчен кирәкле тикшеренүләр һәм эшләнмәләр нәтиҗәләреннән файдаланып, үзебездә эшләнгән технологияләр булдыруда активлыгын билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны хупларга.

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында үстерү программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

– «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең уку-укыту, җитештерү, социаль инфраструктурасын үстерүгә ярдәм күрсәтү мөмкинлеген карарга;

– «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе потенциалын Татарстан Республикасында мәгариф һәм фән үсеше, фәнни-технологик үсеш программаларын гамәлгә ашыруга максималь җәлеп итүне анализларга һәм аның буенча чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы белән берлектә Татарстан Республикасында эшкуарлыкны үстерү програмалары кысаларында студент проектларына грант ярдәмен һәм ярдәмнең башка рәвешләрен күрсәтү мөмкинлеген эшләүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1838-VI ДС